КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 16 май г.Казань № 599

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2015 ел, 11 июнь, 427 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2015 ел, 11 июнь, 427 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 17 май, 321 нче; 2016 ел, 9 июль, 465 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 610 нчы; 2017 ел, 24 август, 598 нче; 2018 ел, 11 апрель, 447 нче, 2019 ел, 12 апрель, 280 нче;

2021 ел, 28 апрель, 288 нче; 2021 ел, 3 август, 676 нчы; 2021 ел, 1 декабрь, 1152 нче; 2022 ел, 28 февраль, 184 нче; 2022 ел, 13 август, 805 нче; 2022 ел, 26 август, 907 нче; 2022 ел, 14 ноябрь, 1206 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018 – 2025 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит оешмасы чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибендә:

1.1 пунктта «2018 – 2024 елларга» сүзләрен «2018 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга, «2014 – 2024 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.7 пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

егерме дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

2.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

а) төбәк проектларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашуга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия акчасы һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия биргәндә:

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашырганда – комплекслы хезмәтләр күрсәтелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Килешүдә билгеләнгән саны;

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашырганда – экспортка ярдәм үзәге хезмәтләре нәтиҗәләре буенча экспорт контрактлары төзегән экспортерлар – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Килешүдә билгеләнгән саны;

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының дүртенче абзацында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашырганда – бизнес алып барырга теләгән, яңа гына эшли башлаган һәм эшләгән, хезмәтләр күрсәтелгән уникаль гражданнарның Килешүдә билгеләнгән саны;

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашырганда – ярдәм күрсәтелгән, шул исәптән уку программаларын үткән үзмәшгуль гражданнарның Килешүдә билгеләнгән саны;

Бу пунктчада күрсәтелгән нәтиҗәләргә ирешү срогы – субсидия бирелгән елның 20 декабреннән дә соңга калмыйча.

б) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия биргәндә:

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашырганда – ярдәм күрсәтелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Килешүдә билгеләнгән саны;

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда – ярдәм күрсәтелүче үзмәшгуль гражданнарның Килешүдә билгеләнгән саны;

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашырганда – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына күрсәтелгән, Килешүдә билгеләнгән хезмәтләр саны;

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашырганда – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен экспортка ярдәм үзәге тарафыннан үткәрелгән чараларның Килешүдә билгеләнгән саны;

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының дүртенче абзацында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашырганда – бизнес алып барырга теләгән, яңа гына эшли башлаган һәм эшләгән уникаль, хезмәтләр күрсәтелгән гражданнарның Килешүдә билгеләнгән саны;

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашырганда – үзмәшгуль гражданнарга күрсәтелгән мәгълүмат-консультация һәм белем бирү хезмәтләренең Килешүдә билгеләнгән саны;

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының алтынчы абзацында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашырганда – онлайн һәм офлайн массакүләм мәгълүмат чараларында, социаль медиаларда басылып чыгуларның (басмаларның) Килешүдә билгеләнгән саны;

Бу Тәртипнең 1.3 пунктының «в» пунктчасында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашырганда – «Тикшерелгән бизнес» сайтындагы мәгълүмат белән идарә итүнең модернизацияләнгән функционалы һәм эшмәкәрләр (шул исәптән үзмәшгуль гражданнар) өчен «Тикшерелгән бизнес» сайтында Килешүдә билгеләнгән интерактив чек-битләр.

Бу пунктчада күрсәтелгән нәтиҗәләргә ирешү срогы – субсидия бирү елының 31 декабреннән дә соңга калмыйча.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин